**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәре (муниципаль тур, 2018-2019 уку елы) 11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 180 минут**
**Максималь балл – 48 балл**

**I. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (12 балл).**

1. Повесть жанрына хас үзенчәлекләрне А.Гыйләҗевның "Өтәч менгән читәнгә" әсәре мисалында аңлатыгыз. Үз фикерегезне дәлилләп языгыз (10 балл).

2. Әсәрдә дуслыкны, яшәү кыйммәтләрен символлаштырган образны язып куегыз (2 балл).

**II. Әдәби иҗатка караган биремнәр (26 балл).**

1. Аксубай районы Иске Кармәт авылы – Тобол губернасы – Уфа – Казан – Покровка. Әлеге урыннар кайсы әдип исеме белән бәйләнгән? (3 балл).

2. Бу әдип әдәбиятның кайсы төрендә иҗат итә? Бер җөмлә белән язып куегыз (3 балл).

3. Х.Туфанның лирик героена нинди сыйфатлар хас? Үз фикерегезне дәлилләп языгыз (10 балл).

4. Х.Туфанның иҗатына үз чорына хас нинди сыйфатлар хас? Үз фикерегезне дәлилләп языгыз (10 балл).

**III. Иҗади эш (10 балл).**

Түбәндәге сүзләрне Х.Туфанның танылган әсәреннән бер строфалык шигырь итеп формалаштырыгыз: *иде, сары, күңелсез, иде, көз, каеннар, кыраулы, иде, җирнең, астралар, шушындый, гөлләр, чагы*.